ГЛАВА НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail:Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“28 ” октябрь 2019ел | № 6

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегенең Сәртек авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Сәртек авылы, Хади Такташ урамы 12 йорт адресы буенча урнашкан Сәртек авылы кибете бинасы янында 2019 елның 13 ноябрендә сәгать 10.00 гә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Сәртек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегенең Сәртек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Сәртек авылында Муса Җәлил урамы юлын вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
- Сәртек авылындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башкарма комитетына Сәртек авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степанов